**Татарстан Республикасы Азнакай районы**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №287-34 «28» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы 2018 елның 12 ноябрендәге 210-31 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (22.04.2019 №247-35, 12.12.2019 №300-41, 22.10.2020 №19-2; 26.08.2021 №75-9, 12.10.2022 №172-19, 30.12.2022 №200-21, 18.04.2023 №222-24 карарлар редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы 2018 елның 12 ноябрендәге 210-31 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» Нигезләмәгә (22.04.2019 №247-35, 12.12.2019 №300-41, 22.10.2020 №19-2; 26.08.2021 №75-9, 12.10.2022 №172-19, 30.12.2022 №200-21, 18.04.2023 №222-24 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.1 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне минималь рөхсәт ителгән бәядән сату;»;

1.2. 9.3 пунктындагы 13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) җиңүчеләрне билгеләү тәртибе (аукцион, махсуслаштырылган аукцион, конкурс уздырганда), яисә сатып алучыларны (дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне минималь бәяләү буенча сатканда), яисә дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне сатып алу хокукы булган затларны (аны гавами тәкъдим ярдәмендә сатканда) билгеләнә»;

1.3. 9.9 пунктының 6 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта, сәүдә җиңүчесе - физик затның исеме яисә юридик затның исеме, аукционда бердәнбер катнашучы дип санала.

2. Әлеге карарның 1.1., 1.2., 1.3 пунктлары 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин